Р. З. Хәйдәрова, Н. Г. Галиева

# ТАТАР ТЕЛЕ



1

Укытучылар өчен методик кулланма

«Татармультфильм»

УДК 81.432.3-99(=411.2)я72
ББК 811.512.145(073.5)
Х18

Фәнни редакторы
**Р. З. Хәйдәрова**

*Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всего издания или его части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**Хайдарова, Р. З. и др.**
Х18 Государственный (татарский) язык Республики Татарстан: Татар теле. 1 класс: книга для учителя к учебнику для общеобразовательных организаций начального общего образования (для обучающихся, не владеющих татарским языком)/ Р. З. Хайдарова, Н. Г. Галиева. — Казан: Татармультфильм, 2024. — 44 с.

ISBN 978-5-906508-45-4

УДК 81.432.3-99(=411.2)я72
ББК 811.512.145(073.5)

ISBN 978-5-906508-45-4
© «Татармультфильм» нәшрияты, 2024

Р. З. Хәйдәрова, Н. Г. Галиева

# ТАТАР ТЕЛЕ

## 1 нче сыйныф

**Укытучылар өчен методик кулланма**

*Татарстан Республикасы*
*Мәгариф һәм фән министрлыгы*
*тарафыннан тәкъдим ителә*

Казан
2024

## «Татар теле» укыту-методик комплекты белән эшләү үзенчәлекләре

Федераль дәүләт башлангыч белем бирү стандартында күрсәтелгәнчә, төп белем бирүнең башлангыч этабы гомуми белем бирүнең нигезе булып тора. Аның төп максаты — балаларда белем һәм күнекмәләр булдыру белән беррәттән, аларның уку эшчәнлеген, универсаль уку гамәлләрен формалаштыруга да нигез салу. Беренче сыйныфта укучы рус телле балаларга тәкъдим ителгән укыту-методик комплекты (УМК) Федераль дәүләт стандартларының укыту процессын оештыруга караган төп таләпләренә һәм психология, педагогика фәннәренең яңа казанышларына таянып, шулай ук тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология нигезендә укыту принципларын исәпкә алып төзелде.

Укыту-методик комплекты түбәндәге компонентлардан тора:

1. Дәреслек.
2. Дәреслекнең электрон формасы.
3. Укытучы өчен методик ярдәмлек.

Укыту-методик комплекты аша татар телен дәүләт теле буларак укыту түбәндәге максатларны күзаллый:

— телне балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән сфераларда аралашу чарасы буларак өйрәнү;

— укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерү;

— универсаль уку гамәлләрен формалаштыру, аларны мөстәкыйль уку эшчәнлегенә әзерләү;

— укучыларның күпмилләтле җирлектә аралашу культурасын формалаштыру;

— укучыларны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү.

Укыту-методик комплектына эчтәлек сайлау Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 18.05.2023 елгы 372 нче санлы «Башлангыч гомуми белем бирүнең федераль эш программасын раслау турында» хатына (теркәлү вакыты: 12.07.2023 ел, №74229) һәм тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына нигезләнде.

**Телне аралашу аша өйрәнү принцибы** нигезендә УМК өчен материал беренче сыйныф балаларының аралашу сфераларын исәпкә алып сайланды.

7–8 яшьлекләр тормышында уен, өй һәм уку хезмәте, гаиләдә һәм дуслар белән аралашу зур урын алып тора. Шулай ук балалар хайваннар турында сөйләшергә, әкиятләр тыңларга яраталар.

Дәреслеккә түбәндәге аралашу темалары кертелде: «Әйдәгез, танышабыз!», «Урман дусларыбыз», «Спорт бәйрәме», «Мәктәптә», «Йорт хайваннары һәм кошлары», «Яшелчәләр», «Кыш җитте», «Сәламәт бул!», «Безнең гаилә», «Кибеттә», «Шәһәрдә, авылда», «Җәй җитә».

Эчтәлек балалар бакчасында өйрәнелгән лексиканы сөйләмдә куллануда камилләштерүне күзә тота. **Күрсәтелгән темалар буенча сөйләшү өчен продуктив лексика якынча 210 сүз тәшкил итә.**

**Уку эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы.** Кече яшьтәге мәктәп балалары — эмоциональ, хәрәкәтчән балалар. Алар тиз арый, бала материалны үзе өчен кызык булса гына, үзенең ихтыяҗына туры килсә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Күрсәтелгән психологик үзенчәлекләр дәреслеккә предмет эчтәлеген сайлаганда исәпкә алынды. Дәреслеккә сайланган материал әкияти сюжетлар, балаларның кечкенә вакытта үзләре ишеткән геройлары (Карлсон, Буратино, Винни-Пух һ.б.) аша таныштырыла барды. Шулай ук, балалар Г.Тукай әсәрләре геройлары белән танышалар: Гали, Акбай, Күбәләк, Кояш, Алмагач, Сандугач. Бу геройлар, аралашу ситуацияләрен имитацияләгәндә, төп катнашучылар булып торалар.

**Укучылар үзләштерергә тиешле лингвистик материалны** билгеләү түбәндәге схема аша оештырыла:

Аралашу сферасында социаль контактларны, сөйләм ситуацияләрен ачыклау

↓

Сөйләшү, сөйләм предметын билгеләү

↓

Сөйләм бурычларын ачыклау

↓

Сөйләм үрнәкләрен билгеләү

↓

Тиешле лингвистик материалны сайлау

Мондый юл белән укучылар үзләштерергә тиешле лингвистик материалны билгеләү Федераль дәүләт башлангыч белем бирү стандарты таләп иткән **системалы-эшчәнлекле концепциягә нигезләнә:** башта системаны барлыкка китерә торган төп компонент — ахыргы нәтиҗә (программа нигезендә билгеләнгән эчтәлек буенча аралашу мөмкинлекләре) билгеләнә, аннан соң гына темалар буенча аралашуны тәэмин итәрлек лингвистик материал сайлап алына.

**Укыту процессын индивидуальләштерү принцибы.** Балаларның истә калдыру сәләтләре төрлечә. Дәрескә алынган сөйләм материалын дәрес азагында һәр бала да үзләштереп бетермәскә мөмкин. Хәтердә калдыруның индивидуаль үзенчәлекләрен истә тотып, дәреслектәге күнегүләр системасы шундый итеп урнаштырылды, бер үк материалның бер дәрес дәвамында кабатлануы, аннан соң тема буенча дәресләр дәвамында, шулай ук темалар бәйләнешендә кабатлана баруы тәэмин ителде. Дәреслеккә һәр дәрес буенча, нигездә, бары яңа материал гына кертелә барды Ләкин һәр сүзне, өйрәнелгән грамматик категорияне, аралашу өчен кирәкле сөйләм үрнәкләрен системалы кабатлатып бару УМКның төп бурычы булды.

**Телне ятлап түгел, ә актив фикерләп өйрәнү принцибы** — чит тел өйрәнүдәге төп принципларның берсе. Укучыларның актив фикер эшчәнлеген дәрестә кулланылган күнегүләр системасы тәшкил итә. Күнегүләрнең биреме шулай итеп төзелде ки, алар укучыларда универсаль уку гамәлләрен формалаштыруга шарт тудыралар. Укучыларның телне актив фикерләп өйрәнүләрен, әлбәттә, аралашуны хәтерләтә торган ситуатив күнегүләр тәэмин итә. Мондый күнегүләр яңа лексик, грамматик материал белән таныштырганда да (бу очракта мотивация тудыру ролен башкара), камилләштерү һәм мөстәкыйль сөйләм этабында да кулланыла ала. Әйтик, «Без мәктәпкә барабыз» темасы буенча түбәндәге ситуатив күнегүләрне кулланырга була.

1. Скажи о том, что у тебя нет тетради (линейки, книги).
   Минем дәфтәрем (линейкам, китабым) юк.
2. Как спросишь у друга, есть ли у него тетрадь (линейка, книга)?
   Синең дәфтәрең (линейкаң, китабың) бармы?
3. Предложи другу тетрадь (линейку, книгу).
   Мә сиңа дәфтәр (линейка, китап).
4. Как скажешь о том, что ты учишься в первом классе?
   Мин беренче сыйныфта укыйм.

5. Скажи о том, что:
   — ты идёшь в школу;
     Мин мәктәпкә барам.
   — ты учишься в школе;
     Мин мәктәптә укыйм.
   — это учительница;
     Бу укытучы.
   — это ученик (ученица);
     Бу укучы.
   — ты хорошо учишься.
     Мин яхшы укыйм.

Дәреслеккә кызыклы сораулар, чагыштыруны, анализлауны, логик фикерләүне таләп иткән төрле биремнәр кертелде. Мондый биремнәрне балалар кызыксынып эшли, шул ук вакытта өйрәнелгән сөйләм үрнәкләре дә кабатлана. Дәреслектәге биремнәр белән генә чикләнмичә, укытучы шундый биремнәрне өстәмә әзерләсә, әлбәттә, дәресләр тагын да нәтиҗәлерәк була.

**Телне функциональ төстә өйрәнү принцибы.** Бу принцип нигезендә грамматик материал түбәндәге таләпләр буенча сайланды:

— грамматик материал коммуникатив максаттан, аралашу хаҗәтеннән һәм куллану ешлыгыннан чыгып билгеләнде;

— грамматик материалның күләмен, теоретик авырлыгын билгеләгәндә, укучыларның үзләштерү мөмкинлекләре исәпкә алынды;

— грамматик материалның бирелеш эзлеклелеге академик тәртиптә түгел, ә аралашу хаҗәтеннән чыгып билгеләнде;

— грамматиканы сөйләм берәмлеге буларак өйрәнү күздә тотылды: иң беренче чиратта грамматик категориянең формасына түгел, ә аның функциясенә игътибар ителде: хәбәр итү, сорау, риза булу һ.б. Берникадәр грамматик материал теоретик формада бирелмичә, ә лексик-грамматик төзелмәләр формасында тәкъдим ителде. Аларны үзләштерү сөйләм ситуацияләре нигезендә оештырылды. Ә җиңелрәк дип саналган грамматик материал филологик формада, кагыйдәләр нигезендә өйрәнелә барды.

Укыту-методик комплектының тагын бер үзенчәлеге шунда: **сөйләм эшчәнлеге төрләренә бер-бер артлы түгел, ә параллель, бер-берсенә бәйле рәвештә өйрәтү бурычы куела.** Ягъни һәр дәрестә сөйләм эшчәнлегенең дүрт төре дә катнаша, һәм дәрес максатында күрсәтелгән сөйләм

дозасы сөйләм эшчәнлегенең дүрт төре аша да үтеп чыга. Аралашу процессы сөйләшү (диалогик, монологик сөйләм), ишетеп аңлау, уку һәм язу аша оештырыла. Алар арасында төп урынны сөйләшү алып тора.

**I Сөйләшү**

**Диалогик сөйләм:**

1 нче сыйныфта дәрес вакытының 70–80% ын сөйләшергә өйрәтү ала. Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

— сайланган эчтәлек аша әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;

— дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

**Монологик сөйләм:**

— җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеген сурәтләп сөйли белү;

— өйрәнелгән темалар буенча кечкенә информация бирә белү.

**II Ишетеп аңлау (аудирование)**

Аралашу өчен төп шартларның берсе — әңгәмәдәшләрнең бер-берсенең сөйләмен аңлавы. 1 нче сыйныфта ишетеп аңларга өйрәтүнең бурычлары түбәндәгеләр:

— нормаль темп белән әйтелгәннең ишетү аша мәгънәсен аңларга, аңлаган турында фикер йөртергә, аралашуда куллана белергә өйрәтү;

— сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетү аша аерырга өйрәтү;

— ишетү хәтеренең күләмен үстерү.

**III Уку**

Уку эшчәнлеген (чтение) оештырганда, укытучы укучыларның «Букварь» белән эшләүләрен даими рәвештә күзәтә, башлангыч сыйныф укытучысы белән элемтәдә тора.

Уку эшчәнлеген оештыру буенча дәреслектә материал түбәндәге принциплар нигезендә бирелде:

1. Авазларны өйрәнү «Букварь»ны өйрәнү белән параллель яисә аз гына соңга калып бара.

2. Татар әлифбасына гына хас **ә, ө, ү, җ, ң, һ** хәрефләре **а, о, у, ж, н, х** хәрефләре белән бергә бирелә.

3. Бер үк хәрефнең төрле авазлар белдерүе, хәреф белән таныштырганда ук, транскрипция билгеләре ярдәмендә күрсәтелә. Балалар транскрипция билгеләрен укый һәм куллана белсеннәр өчен, дәреслектә махсус күнегүләр системасы бирелде.

4. Интерференция күренешеннән котылу өчен, күп кенә дәресләрдә рус теленнән кергән сүзләрдә һәм татар теленең үз сүзләрендә бер үк хәрефнең төрле авазлар белдерүенә мисаллар китерелде. Мәсәлән: *алма — автобус; кош — помидор* һ.б.

5. Уку техникасын үстерүгә ярдәм итә торган рифмовкалар, җырлар, рифмалаштырылган әкиятләр бирелде. Үзләштерү дәрәҗәсенә карап, укытучы аларны арттыра яки кимәтә ала.

**IV Язу**

1 нче сыйныфта язуга өйрәтүнең төп максаты — татар әлифбасы хәрефләрен, программага кергән актив сүзләрне дөрес, матур язарга өйрәтү. Язуны коммуникатив максатларда куллана белү мөмкинлегенә басым ясалды: дәреслекләрдә уенга чакыру, иптәшеңә яки әниеңә записка язу, төрле бәйрәмнәр белән котлау, уенга чакыру язу, үзең турында кечкенә белешмә яза белү күнекмәләрен үстерү буенча биремнәр урын алды.

Дәрес бирүнең планнарын төзегәндә, түбәндәгеләрне исәпкә алырга тәкъдим ителә:

1. Бер дәрес материалын икенче дәрестә кабатлау зарур. Кайсы материалны ничек кабатлатасын, нинди күнегүләр өстәсен укытучы балаларның уку мөмкинлекләреннән чыгып үзе хәл итә.

2. Укучыларның уку эшчәнлеген оештырганда, аларның фикерләү сәләтләре, үзләштерү мөмкинлекләре төрле булуын исәпкә алып, укытучы дәреслектә бирелгән эчтәлекне мөмкин кадәр дифференциальләштерергә, балаларның индивидуаль үзенчәлекләренә туры китереп, күнегүләр системасын бирүне планлаштырырга тиеш.

3. Дәресләрдә нинди универсаль уку гамәлләре белән эшләү кирәклеген сөйләм үстерү максатында күрсәтү зарур. Искәртергә кирәк, уку максатын (сөйләм бурычын) аңлап, аңа тәңгәл килерлек мәгълүматны сайлый белү; уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү; парлап эшли белү; бер кабат ишеткәнне аңлау, коммуникациягә керә белү кебек универсаль гамәлләр белән эшләү, дәрес максатларында күрсәтелмәсә дә, һәр дәрестә дә оештырылырга тиеш.

4. Дәресләрдә рус телен куллануга бик сак килергә кирәк. Кайсы очракларда рус телен куллану максатка ярашлы була? Материалны кабул итүгә

ихтыяҗ тудырганда; грамматик материалны аңлатканда; яңа материалны презентацияләгәндә; балаларны эмоциональ хуплаганда; ситуатив күнегүләр кулланганда; дәресне йомгаклаганда, балаларның аралашу, аңлау телен куллану кулайрак. Ә инде дәрес алып бару өчен кулланылган күрсәтмәләр акрынлап тулысынча татарча әйтелешкә күчәргә тиеш.

5. Дәрес планында белем бирү максатын билгеләгәндә, укытучы үзенең эш программасындагы темалар буенча билгеләнгән предмет нәтиҗәсен аеруча истә тотарга тиеш. Искәртергә кирәк: предмет нәтиҗәсе — укучыларның лексиканы, грамматиканы истә калдырулары гына түгел, ә аларны аралашу максатында куллана алулары. Һәм һәр дәрестә балалар үзләренең татарча нәрсә әйтә, ничек аралаша алуларына йомгак ясап барырга тиеш.

6. Дәрес этапларында укучыларга уку бурычы кую, укучыларның аны аңлап эш итүләренә, эш төгәлләнгәндә, үзләренең уку хезмәтләренә бәя бирә белүләренә ирешү федераль дәүләт стандартлары таләпләре нигезендә эшләүнең бер күрсәткече булып тора, һәм бу юнәлешкә һәрдаим игътибар итеп эшләү зарур.

Укытучы өчен методик ярдәмлек түбәндәге өлешләрдән тора:

— укыту-методик комплекты белән эш үзенчәлекләренә аңлатма;

— предмет буенча федераль эш программасы нигезендә төзелгән тематик планның үрнәге;

— ишетеп аңлау күнегүләре;

— дәресләрдә куллану өчен уеннар.

## Ишетеп аңлау күнегүләре

### Әйдәгез танышабыз!

### 1–2 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**
Исәнмесез, мин, кем, Шүрәле, исәнме, ничек.

**2. Прослушайте и укажите слова, обозначающие людей.**
Исем, малай, ничек, көн, кыз, Шүрәле, укытучы, укучы.

**3. Прослушайте и укажите предложения, в которых выражен вопрос.**
Синең исемең ничек? Мин — Азат. Син кем? Мин — малай.

**4. Прослушайте и укажите предложения, в которых есть татарские имена.**
Мин — Саша. Мин — Рамил. Мин — Лена. Мин — Алсу.

**5. Какие предложения говорят при встрече, а какие — при прощании?**
Исәнме! Сау бул! Исәнмесез! Хәерле көн! Сау булыгыз!

### 3–7 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**
Исәнмесез, әйе, юк, песи, Акбай, күбәләк.

**2. Укажите слово, в которых есть звук [ң].**
Юк, мин, синең, исем, күбәләк.

**3. Назовите слова, которые выражают отрицание.**
Әйе, юк, түгел, малай, кыз.

**4. Укажите предложения, где выражен вопрос.**
Бу малаймы? Бу — малай. Бу кызмы? Бу — кыз. Бу Машамы? Бу — Маша. Бу синме? Бу мин.

**5. Укажите предложения, где выражен отрицательный ответ.**

Бу Ләйсәнме? Юк, бу Ләйсән түгел. Бу Ленамы? Әйе, бу — Лена. Бу Маратмы? Юк, бу Марат түгел.

**6. Прослушайте и укажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Бу Азат. Бу Азат түгел.
2) Исемең ничек? Синең исемең ничек?
3) Мин — Ләлә. Әйе, мин Ләлә.

**8–10 нчы дәресләр**

**1. Прослушайте и укажите вежливые слова.**

Кем, исәнме, малай, рәхмәт, түгел, сау бул.

**2. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *кем*?**

Мин, рәхмәт, малай, кыз, юк, Казан.

**3. Прослушайте и укажите названия городов.**

Казан, түгел, малай, Чаллы, Алабуга, исем, Түбән Кама, яшим.

**4. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *кайда*?**

Ничек, Казанда, мин, Чистайда, кыз, Чаллыда, Алабугада.

**5. Прослушайте и определите, что изменено во втором предложении каждой пары?**

1) Мин Казанда яшим. Мин Минзәләдә яшим.
2) Мин Чаллыда яшим. Мин Алабугада яшим.

**6. Прослушайте и укажите, сколько предложений в тексте.**

Минем исемем Надя. Мин Чаллыда яшим. Илдар Казанда яши.

**7. Прослушайте два предложения и укажите, что пропущено во втором предложении каждой пары.**

1) Мин шәһәрдә яшим. Шәһәрдә яшим.
2) Азат авылда яши. Ул авылда яши.
3) Ренат Чистайда яши. Ул Чистайда яши.

## 11–12 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова с мягкими гласными звуками.**

Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун.

**2. Слушайте и в паузах поднимите карточки с соответствующей цифрой.**

Бер, дүрт, алты, өч, җиде, тугыз, ике, биш, сигез, ун.

**3. Прослушайте и скажите, какие слова пропущены в логическом ряду.**

Бер, ике, өч, ..., биш, алты, ..., сигез, ..., ун.

**4. Прослушайте и укажите слова-вопросы.**

Сиңа, ничек, миңа, кем, яши, ничә, ул.

**5. Прослушайте предложения и укажите слова, отвечающие на вопрос *кайда*?**

1) Мин Казанда яшим. 2) Мин авылда яшим. 3) Мин Минзәләдә яшим. 4) Мин шәһәрдә яшим.

**6. Прослушайте диалог и разыграйте его.**

— Синең исемең ничек?
— Мин — Әлфия.
— Сиңа ничә яшь?
— 7 яшь.
— Син кайда яшисең?
— Мин Чаллыда яшим.
— Ничәнче сыйныфта укыйсың?
— Беренче сыйныфта.

**7. Прослушайте текст и определите, сколько в нем предложений.**

Минем исемем — Ләйсән. Мин Казанда яшим. Миңа 7 яшь. Мин беренче сыйныфта укыйм.

## Урман дусларыбыз

### 13–17 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ө].**
Бүре, керпе, төлке, тиен, үрдәк, өч, көн.

**2. Прослушайте и укажите слова с мягкими гласными звуками.**
Куян, бүре, аю, төлке, керпе, авыл, үрдәк, кәҗә, фил.

**3. Прослушайте и в паузах скажите каждое слово во множественном числе.**
Аю, бүре, төлке, керпе, авыл, куян, тиен.

**4. Прослушайте и назовите лишнее слово.**
Аю, бүре, төлке, кыз, куян, тиен.

**5. Прослушайте и выберите правильный по смыслу вариант в каждой паре.**
1) Аю авылда яши. Аю урманда яши.
2) Бүре шәһәрдә яши. Бүре урманда яши.

**6. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нинди*?**
Бүре, зур, усал, төлке, килә, кечкенә, китә, куркак, хәйләкәр.

**7. Прослушайте и скажите, кто живет в тереме.**
Аю, бүре, төлке, керпе, бака, тычкан.

## Спорт бәйрәме

### 18–23 нче дәресләр

**1. Прослушайте и покажите действия в движениях.**
Йөгер, йөз, сикер, оч, утыр, бас.

**2. Прослушайте и укажите слова с твёрдыми гласными звуками.**
Йөгер, йөз, сикер, оч, утыр, бас.

**3. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Әлфия, утыр! Әлфия, утыр әле.
2) Олег, бас! Олег, бас әле.
3) Сания, йөгер! Сания, йөгер әле.

**4. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нишли*?**

Малай, утыра, баса, сикерә, килә, кыз, йөзә, зур, оча, усал.

**5. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нәрсә?***

Машина, Оля, урман, туп, шар, курчак, малай, кыз, шакмак, скакалка.

## Мәктәптә

### 24–25 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**

Китап, дәфтәр, каләм, акбур, бетергеч, көндәлек.

**2. Прослушайте и укажите слова со звуком [қ].**

Китап, дәфтәр, каләм, акбур, бетергеч, карандаш.

**3. Прослушайте и добавьте к каждому слову окончание множественного числа.**

Китап..., дәфтәр..., каләм..., акбур..., бетергеч...

**4. Укажите лишнее слово в логическом ряду.**

1) Дәфтәр, китап, аю, бетергеч.
2) Йөгерә, сикерә, яза, оча, акбур.

### 26–27 нче дәресләр

**1. Прослушайте вопросы, дайте утвердительный ответ.**

1) Сумкада бетергеч бармы?
2) Сумкада китап бармы?
3) Сумкада дәфтәр бармы?
4) Сумкада каләм бармы?

**2. Прослушайте вопросы и дайте ответ.**
— Сиңа китап кирәкме?
— ... .
— Сиңа дәфтәр кирәкме?
— ... .
— Сиңа каләм кирәкме?
— ... .

**3. Прослушайте текст и укажите лишнее предложение.**
Айдар беренче сыйныфта укый. Ул чиста, матур яза. Тиен биек сикерә.

**4. Прослушайте текст и ответьте на вопросы.**
Айдар беренче сыйныфта укый. Ул чиста, матур яза.
*Вопросы:*
1) Айдар ничәнче сыйныфта укый?
2) Ул ничек яза?

**Йорт хайваннары һәм кошлары**

**28–33 нче дәресләр**

**1. Прослушайте и укажите, сколько слогов в каждом слове.**
Сыер, сарык, ат, кәҗә, дуңгыз, әтәч, тавык, каз, үрдәк, кош.

**2. Прослушайте и укажите слова с одним слогом.**
Сыер, сарык, ат, кәҗә, әтәч, тавык, каз, кош.

**3. Прослушайте и в паузах скажите каждое слово во множественном числе.**
Сыер, сарык, ат, әтәч, тавык, каз, үрдәк.

**4. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**
Сыер, сарык, әтәч, тавык, каз, үрдәк.

**5. Прослушайте и укажите словавопросы.**
Авыл, кая, шәһәр, кемгә, бара, нишли, кәҗә, нәрсә.

**6. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *кая?***

Мин урманга барам. Ул бассейнга бара. Коля мәктәпкә бара. Петя авылга кайта. Әни шәһәргә китә.

**7. Прослушайте и скажите, как изменятся слова при ответе на вопрос *кая?***

Урман... , бассейн... , мәктәп... , авыл... , шәһәр... , өстәл... , урындык... .

**8. Прослушайте и скажите, как изменятся слова при ответе на вопрос *кайдан?***

Урман... , бассейн... , мәктәп... , авыл... , шәһәр... , өстәл... , урындык... .

**9. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Ул бассейннан кайта. Ул кинодан кайта.
2) Ул Чаллыга бара. Ул Чаллыдан кайта.
3) Мин Казанга барам. Мин Казаннан кайтам.

**10. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *кайдан?***

Малай урманнан кайта. Кыз авылдан кайта. Петя шәһәрдән килә. Мин мәктәптән кайтам.

**11. Прослушайте диалог и постарайтесь его разыграть.**

— Сәлам, Костя!
— Сәлам, Наил!
— Син кая барасың?
— Стадионга.
— Ә син кайдан кайтасың?
— Мин стадионнан кайтам.

## Яшелчәләр

### 34–36 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и скажите, кто не является персонажем сказки «Репка»?**

Бабай, әби, әни, кыз, эт, песи, тычкан.

**2. Прослушайте и укажите персонажи в том порядке, в каком встречаются в сказке.**

Тычкан, әби, кыз, бабай, эт, песи.

**3. Прослушайте и выделите то предложение, которое не соответствует сказке.**

Бабай шалкан чәчә. Шалкан зур булып үсә. Бакчада кыяр үсә. Бабай шалканны тарта. Шалкан чыкмый да чыкмый.

**4. Прослушайте слова и укажите овощи, с которыми варят щи.**

Шалкан, суган, кыяр, помидор, кәбестә, бәрәңге, кабак, кишер.

### 37 нче дәрес

**1. Прослушайте и укажите слова, состоящие из двух слогов.**

Кишер, кыяр, бәрәңге, суган, кабак, чөгендер.

**2. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нәрсә?***

Матур, кишер, тәмле, кыяр, бәрәңге, зур.

**3. Прослушайте и укажите слова, обозначающие овощи.**

Тәмле, кишер, матур, кыяр, су, сибә, бәрәңге, яшелчә.

### Кыш җитте

### 38–41 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нинди?***

Җил, салкын, урам, буран, җылы, кар.

**2. Прослушайте и укажите слова, которые можно употреблять при описании зимней погоды.**

Зур, салкын, уенчык, кар ява, чаңгы, буран.

**3. Прослушайте два текста с описанием зимней погоды. В какую погоду ты бы не пошёл гулять?**

1) Бүген бик салкын. Салкын җил исә. Буран.
2) Бүген көн матур, кояшлы. Салкын түгел, урамда рәхәт.

**4. Прослушайте и укажите слова со звуком [ғ].**

Чаңгы, чана, тимераяк, шугалак, тау, шуа, уйный, Кыш бабай.

**5. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Рәсимә чана шуа. Рәсимә чаңгы шуа.
2) Рөстәм хоккей уйный. Рөстәм хоккей уйнамый.

**6. Прослушайте диалог и укажите вопросительные предложения.**

— Марат, әйдә тауга барабыз.
— Син тауда нишлисең?
— Чана шуам.
— Синең чанаң бармы?
— Әйе.

## 42–43 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, относящиеся к новогоднему празднику.**

Яңа ел, апа, кыш бабай, китап, чыршы, дәфтәр, мәктәп.

**2. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Бәйрәмгә барасыңмы? Син бәйрәмгә барасыңмы?
2) Сине бәйрәм белән котлыйм! Сине Яңа ел бәйрәме белән котлыйм.
3) Син җырлыйсыңмы? Син бәйрәмдә җырлыйсыңмы?

**3. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Мин футбол уйныйм. Син футбол уйнысың.
2) Мин чана шуам. Син чана шуасың.
3) Мин чаңгы шуам. Син чаңгы шуасың.

**4. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Мин шуам. Мин чаңгы шуам.
2) Мин барам. Мин Казанга барам.

**5. Прослушайте текст и ответьте на вопросы.**

Бүген көн матур. Салкын түгел. Балалар тауга баралар. Алар чаңгы, чана шуалар..

*Вопросы:*

1) Көн нинди?
2) Балалар кая баралар?
3) Алар нишлиләр?

## Сәламәт бул!

### 44–47 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слово со звуком [w].**

Баш, бит, чәч, борын, авыз, кул, аяк.

**2. Прослушайте и укажите слова со звуком [қ].**

Баш, бит, чәч, бармак, борын, авыз, кул, аяк.

**3. Прослушайте и укажите слова, состоящие из одного слога.**

Баш, бит, чәч, бармак, борын, авыз, кул, аяк, бит.

**4. Прослушайте и укажите лишние слова в логическом ряду.**

Баш, бит, чәч, туфли, бармак, борын, күлмәк, авыз, кул, аяк.

**5. Прослушайте и укажите слова, состоящие из двух слогов.**

Башым, авырта, кулым, авыртмый, кул, аяк, борыным, авыз,

## Безнең гаилә

### 48–50 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**

Әти, әни, әби, бабай, сеңел, эне, апа, абый.

**2. Прослушайте и укажите, сколько слогов в каждом слове.**

Әти, әни, әби, бабай, сеңел, эне, апа, абый.

**3. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**

Әти, әни, әби, чәй, бабай, сеңел, эне.

**4. Прослушайте текст и расскажите содержание.**

Бу безнең гаилә. Безнең гаилә зур түгел. Гаиләдә дүрт кеше. Безнең гаиләдә әни, әти, абый һәм мин бар.

**51–53 нче дәресләр**

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ө].**

Гөбәдия, чәкчәк, бәлеш, өчпочмак, ипи, ит, шикәр, чәй.

**2. Прослушайте и укажите слова, состоящие из трёх слогов.**

Гөбәдия, чәкчәк, бәлеш, өчпочмак, ипи, ит, шикәр, чәй.

**3. Прослушайте и скажите слова по образцу.**

*Образец:* өчпочмак — бу өчпочмакмы?

Гөбәдия, бәлеш, өчпочмак, ипи, ит, шикәр, чәй, чәкчәк.

**4. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**

Гөбәдия, чәкчәк, бәлеш, тәлинкә, өчпочмак, ипи, ит, шикәр, чәй.

**Кибеттә**

**54–55 нче дәресләр**

**1. Прослушайте и укажите слово со звуком [ө].**

Шикәр, кәнфит, ипи, сөт, май, аш, чәй.

**2. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нинди*?**

Зур, шикәр, кәнфит, баллы, ачы, май, аш, чәй, тәмле.

**3. Послушайте диалог. Расскажите содержание.**

— Апа, әйтегез әле, сөт бармы?
— Сөт бар.
— Ничә сум?
— 15 сум.

**4. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *мин нишлим?***

Ашыйм, эчәсең, бирә, утырам, ипи кисә, ала, куям.

## 56–58 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите лишнее слово.**
Чалбар, итәк, күлмәк, дәфтәр, бүрек, башлык.

**2. Прослушайте и скажите, что лишнее в логическом ряду слов.**
Кибеттә күлмәк, чалбар, башлык, кәбестә, итәк саталар.

**3. Прослушайте и укажите вопросительные предложения.**
— Бу кибетме?
— Әйе.
— Кибеттә күлмәк бармы?
— Юк.

**4. Прослушайте и укажите, согласны ли вы с переводом (перевод дается на доске или на карточках).**
Миңа әни күлмәк ала. Ул зур түгел. Ул кечкенә түгел. Күлмәк бик матур. Ул зәңгәр.

## Шәһәрдә һәм авылда

## 59–61 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите, сколько слов в предложениях.**
1) Олег шәһәрдә яши. 2) Шәһәр бик матур. 3) Урамнар чиста.

**2. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**
1) Дилә шәһәрдә яши. — Дилә Казанда яши.
2) Шәһәр матур. — Шәһәр матур түгел.
3) Урамнар зур. — Урамнар зур, чиста.

**3. Прослушайте и укажите предложения, где выражен вопрос.**
1) Мин шәһәрдә яшим. 2) Ә син шәһәрдә яшисеңме? 3) Шәһәр зур. 4) Шәһәр зурмы?

**4. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Азат Чаллыга автобуста бара. Азат Чаллыга машинада бара.

2) Саша бассейнга трамвайда бара. Саша бассейнга троллейбуста бара.

### 62–63 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова-вопросы.**

Мәктәп, парк, кайда, кайта, кайдан, Казанда, килә, шәһәр, авыл, кая.

**2. Прослушайте и определите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Мин шәһәрдә яшим. — Мин авылдада яшим.
2) Син шәһәрдә яшисеңме? — Син авылда яшисеңме?
3) Ренат Казанда яши. — Ул Казанда яши.
4) Алия авылда яши. — Алия Түбән Камада яши.

**3. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *кайда*?**

Казанда, мин, Чаллыда, Алабугада, Татарстан.

## Җәй

### 64–66 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова-вопросы.**

Җәй, бара, кая, урман, нишли, гөмбә, күбәләк, җиләк.

**2. Прослушайте и укажите вопросительные предложения.**

— Бу урманмы?
— Әйе.
— Анда җиләк бармы?
— Бар.

**3. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [w].**

Көрәшә, чүлмәк, вата, Сабантуй, җәй, йөгерә, авыл.

## Темалар буенча предмет нәтиҗәләре

| Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек, якынча сәгатьләр саны | Тема буенча предмет нәтиҗәләре |
|---|---|
| **Әйдәгез танышабыз! (12 сәгать)**<br>Танышу. Бер-береңнең исемен сорау, яшәү урынын әйтү. 1 дән 10 га кадәр саннар. | Әңгәмәдәшең исемен сорый белү. Әңгәмәдәшеңнең яшәү урынын сорый һәм үзеңнең кайда яшәвең турында әйтә белү. Бергә уйнарга чакыра белү. |
| **Урман дусларыбыз (5 сәгать)**<br>Кыргый хайваннар, аларның яшәү урыннары. Аларны сурәтләү. | Кыргый хайваннарны, аларның санын әйтә белү. Кыргый хайваннарның кайда яшәгәнен әйтә, аларны сурәтли белү. |
| **Спорт бәйрәме (6 сәгать)**<br>Спорт бәйрәмендә катнашу. | Спорт бәйрәмендә нишләгәнеңне әйтә белү. |
| **Мәктәптә (4 сәгать)**<br>Уку-язу әсбаплары. Уку-язу әсбапларының саны, барлыгы, юклыгы, урыны. Мәктәптә уку хезмәте. | Уку-язу әсбапларын әйтә, үзеңә сорап ала, санын әйтә белү.<br>Предметларның урынын әйтә белү.<br>Мәктәптә уку хезмәтен әйтә белү. |
| **Йорт хайваннары һәм кошлары (6 сәгать)**<br>Йорт хайваннары һәм кошлары, яшәү урыннары. Аларны сурәтләү | Йорт хайваннарын һәм кошларын атый, аларның санын, яшәү урынын әйтә белү.<br>*Кая? кайда? кайдан?* сорауларына җавап бирә белү. |
| **Яшелчәләр (4 сәгать)**<br>Яшелчә исемнәре, саны, аларның төсе, тәме. | Яшелчәләр, аларның санын, төсен, тәмен әйтә, аларны сорап ала белү.<br>Нәрсә яратканыңны, яратмаганыңны әйтә белү. |
| **Кыш җитте (6 сәгать)**<br>Кыш билгеләре. Кышкы уеннар. Яңа ел бәйрәме. | Кыш билгеләрен әйтә, сорый, белү.<br>Чана, чаңгы, тимераякларның барлыгын, юклыгын, нәрсә белән шуганыңны әйтә белү. |
| **Сәламәт бул! (4 сәгать)**<br>Тән әгъзалары. Табибта. | Тән әгъзаларын атый, кайсы җирең авыртканын сорый, әйтә белү. |
| **Безнең гаилә (6 сәгать)** | Гаилә әгъзаларының исемнәрен атый, үз гаиләң турында сөйли белү. |
| **Кибеттә (5 сәгать)**<br>Ашамлыклар. Ашамлыклар кибетендә. Киемнәр. Киемнәр кибетендә. | Ашамлыклар турында, нәрсә ашаганыңны, эчкәнеңне әйтә, кибеттә сатып ала белү.<br>Кием исемнәрен, барлыгын-юклыгын, нинди икәнен әйтә белү. Кибеттә сатып ала белү. |
| **Без шәһәрдә (авылда) яшибез (5 сәгать)**<br>Шәһәрдә. Безнең шәһәр. Мин транспортта барам. | Нинди республикада яшәгәнеңне, шәһәрдә (авылда) сөйли белү. Нинди транспортта барганыңны әйтә белү. |
| **Җәй җитә (3 сәгать)**<br>Күңелле җәй. Җәйге ял. Без Сабан туена барабыз. | Җәй билгеләрен әйтә белү.<br>Сабан туена барганыңны, бәйрәмдә нишләгәнне әйтә белү. |

**Федераль эш программасына нигезләнгән календарь-тематик план**

**1 нче сыйныф**

**I. Мир моего «Я»: Давайте познакомимся. Я и моя семья. Здоровье.**

**II. Мир моих увлечений: Любимые игрушки. Спорт.**

**III. Мир вокруг меня: Моя школа. В магазине. Времена года (зима, лето).**

**IV. Моя Родина: Столицы России и Татарстана. Наш город. Наше село. Животный мир.**

**Сөйләмнең грамматик ягы:**

— исемнәрнең берлек һәм күплек санда кулланылышы;

— исемнәрнең 1, 2, 3 зат тартым белән төрләнеше;

— сорау алмашлыклары: *кем?, нәрсә?, кая?, кайда?, ничә?, ничәнче?, нинди?, нишли?;*

— төсне белдерүче сыйфатлар; «сыйфат+исем» төзелмәсенең күплек сан формасы (яхшы укучылар);

— исемнәрнең юнәлеш, урын-вакыт килеше формалары;

— 1 дән 10 га кадәр микъдар һәм тәртип саннары;

— «сан+исем» төзелмәсенең берлек сан формасы (биш укучы);

— зат алмашлыкларының берлек сан формасы (мин, син, ул);

— зат алмашлыкларының юнәлеш килеше формасы (миңа, сиңа, аңа);

— зат алмашлыкларының иялек килеше формасы (минем, синең, аның);

— «бу» күрсәтү алмашлыгы;

— хәзерге заман хикәя фигыльнең I, II, III зат берлек сан барлык формасы;

— *-мы/-ме, түгел* кисәкчәләре;

— *белән* бәйлегенең исем белән кулланылышы.

| Дәресләр номеры | Теманың дәреслектә бирелеше | Сәгатьләр саны | Предмет нәтиҗәсе |
|---|---|---|---|
| **Әйдәгез танышабыз! — 12 сәгать<br>I Мир моего «Я»** | | | |
| 1–2 | Әйдәгез танышабыз | 2 | Әңгәмәдәшеңнең исемен сорый, үз исемеңне әйтә белү |
| 3–4 | *Бу кем?* соравы һәм аңа җавап формасы.<br>*Бу нәрсә?* соравы һәм аңа җавап формасы | 2 | Бу — күрсәтү алмашлыгын кулланып, *Бу кем? Бу нәрсә?* сораулары аша кирәкле информацияне ала белү |
| 5–7 | *-мы/-ме* сорау кисәкчәләре.<br>Раслау һәм кире кагу формалары.<br>түгел кисәкчәсе | 3 | Ачыклый белү. Кире кага һәм раслый белү:<br>*— Син О́лямы?*<br>*— Әйе́, мин — О́ля.*<br>*(— Мин Оля түгел)* |
| 8–10 | *Син кайда яшисең?*<br>Мин Татарстанда яшим.<br>Мин шәһәрдә (авылда) яшим. | 3 | *Син кайда яшисең?* соравын куя һәм аңа җавап бирә белү.<br>Үзең яшәгән җирлекнең исемен әйтә белү |
| 11–12 | 1 дән 10 га кадәр саннар.<br>*Сиңа ничә яшь?* соравы һәм аңа җавап формасы | 2 | 1 дән 10 га кадәр саннарны әйтә белү.<br>Бер-береңнең яшен сорый һәм җавап бирә белү |
| **Урман дусларыбыз. — 5 сәгать<br>IV Моя Родина** | | | |
| 13–14 | Кыргый хайваннарның исемнәре.<br>Исемнәрнең күплек сан формасы | 2 | Кыргый хайваннарның исемнәрен атый, санын әйтә белү (сан + берлек сандагы исемнәр төзелмәсе).<br>Исемнәрнең күплек сан формасы белән таныштыру |
| 15 | *Нинди?* соравы һәм аңа җавап формасы | 1 | Хайваннарның кайда яшәгәнен әйтә, аларны сурәтли белү *(сыйфат+исем* төзелмәсе*)* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 16–17 | «Теремкәй» рус халык әкияте | 2 | «Теремкәй» әкиятенең эчтәлеген искә төшерү. «Теремкәй» әкиятен сәхнәләштерү |
| **Спорт бәйрәме. — 6 сәгать**<br>**II. Мир моих увлечений** | | | |
| 18–19 | *Нишли?* соравы һәм аңа җавап формасы | 2 | *Нишли?* соравын куя белү. *Йөгерә, йөзә, сикерә оча* фигыльләрен хәзерге заман III зат берлек сан формасында әйтә белү |
| 20–21 | Минем яраткан уенчыкларым. «Сан+исем» төзелмәсе. Сузык авазлар | 2 | Уенчык исемнәрен әйтә белү. Татар телендә сузык авазларны калынлыкта һәм нечкәлектә аера белү |
| 22 | *Син нишлисең?* соравы һәм аңа җавап формасы | 1 | Нинди уенчыклар белән уйнаганыңны әйтә белү |
| 23 | Командалар бирәбез | 1 | *Тор, утыр, бас, йөз, сикер* фигыльләрен II зат берлек сан боерык фигыль формасында әйтә белү |
| **Мәктәптә. — 4 сәгать**<br>**III Мир вокруг меня** | | | |
| 24–25 | Уку-язу әсбапларының исемнәре. Уку-язу әсбапларының саны, төсе, барлыгы, юклыгы. Төсне белдерүче сыйфатлар. «Сыйфат+исем» төзелмәсе | 2 | Уку-язу әсбапларының исемен, санын, төсен, барлыгын, юклыгын әйтә белү |
| 26–27 | *Кайда*? соравы һәм аңа җавап формасы. Уку-язу әсбапларының урыны, сорап алу. Мин, син алмашлыкларының юнәлеш килеше формасы (миңа, сиңа, аңа) | 2 | Уку-язу әсбапларын үзеңә сорап ала, кайда икәнен әйтә белү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Йорт хайваннары һәм кошлары. — 6 сәгать**<br>**IV Моя Родина** | | | |
| 28–29 | Йорт хайваннары һәм кошлары. *Кайда*? соравы һәм аңа җавап формасы | 2 | Йорт хайваннарының һәм кошларының исемнәрен әйтә, саный белү. *Кайда?* соравына җавап бирә белү күнекмәләрен камилләштерү |
| 30 | *Кая? Кемгә?* сорауларына җавап формасы | 1 | *Кая?* соравын үзләштерү һәм, аңа җавап буларак, исемнәрнең юнәлеш килеше формасы белән таныштыру |
| 31 | *Кайдан?* соравы һәм аңа җавап формасы | 1 | *Кайдан?* соравын үзләштерү һәм, аңа җавап буларак, исемнәрнең чыгыш килеше формасы белән таныштыру |
| 32–33 | *Кая? кайда? кайдан?* сорауларына җавап бирү. «Минем этем», «синең этең» структуралары. «Без йоклыйбыз» *тексты* | 2 | *Кая? кайда? кайдан?* сорауларына җавап бирә белүне камилләштерү. Этеңнең барлыгын, юклыгын әйтә белү.<br>«Тыныч йокы» рифмовкасын сөйли белү |
| **Яшелчәләр. — 4 сәгать**<br>**IV Моя Родина** | | | |
| 34 | Без саныйбыз | 1 | *Кая? кайда? кайдан?* сорауларына җавап бирә белүне камилләштерү. 1–10 саннарын искә төшерү |
| 35–36 | «Шалкан» әкиятен уку, сәхнәләштерү | 2 | «Шалкан» әкиятенең эчтәлеге белән таныштыру. Әкиятне сәхнәләштерү |
| 37 | Яшелчә исемнәре | 1 | Яшелчә исемнәрен, санын, аларның төсен, аларны сорап ала белү. Нинди яшелчә яратканыңны әйтә белү |
| **Кыш җитте. — 6 сәгать**<br>**III Мир вокруг меня** | | | |
| 38–39 | Кыш билгеләре | 2 | Кыш билгеләрен әйтә, кышкы уенга чакыра, көн нинди булуын сорый белү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 40–41 | Кышкы уеннар.<br>*Мин, син* алмашлыкларының иялек килеше (минем, синең).<br>Синең чаңгың бармы? | 2 | *Чана, чаңгы, тимераяк* сүзләрен әйтә белү.<br>Бу предметларның барлыгын, юклыгын сорый, әйтә, белү. Аларны сорап ала белү.<br>Чанада, чаңгыда шуганыңны әйтә белү. |
| 42–43 | Яңа ел бәйрәме.<br>*Кая? кайда? кайдан?* сорауларына җавап бирү.<br>Хәзерге заман хикәя фигыльнең I, II, III зат берлек сан барлык формасы | 2 | Бәйрәмгә барганыңны, бәйрәмдә нишләгәнеңне әйтә белү.<br>*Кая? кайда? кайдан?* сорауларына җавап бирә белүне камилләштерү |
| **Сәламәт бул! — 4 сәгать<br>II Мир моих увлечений** | | | |
| 44–45 | Тән әгъзалары исемнәре | 2 | Тән әгъзалары исемнәрен әйтә белү |
| 46–47 | Исемнәрнең I, II, III затта тартым белән төрләнеше.<br>Кай җирең авырта? | 2 | Кай җирең авыртканын сорый, әйтә белү |
| **Безнең гаилә. — 6 сәгать<br>I Мир моего «Я»** | | | |
| 48–50 | Безнең гаилә.<br>Г. Тукай. «Безнең гаилә» шигыре | 3 | Гаилә әгъзаларының исемнәрен атый, үз гаиләң турында сөйли белү.<br>«Безнең гаилә» шигырен сәнгатьле укый белү |
| 51–53 | Татар халык ашлары | 3 | Татар халык ашларының исемнәрен, нинди ризыклар яратканыңны әйтә белү |
| **Кибеттә. — 5 сәгать<br>III Мир вокруг меня** | | | |
| 54–55 | Ашамлыклар кибетендә | 2 | Азык-төлек исемнәрен әйтә белү.<br>Кибеттә сатып ала белү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 56–58 | Киемнәр кибетендә.<br>*Белән* бәйлеге. «Әни белән» төзелмәсе | 3 | Кием исемнәрен, барлыгын-юклыгын, нинди икәнен әйтә белү. Кибеттә сатып ала белү. Исемнәрнең I, II зат берлек санда тартым формасын сөйләмдә куллануны камилләштерү |
| **Шәһәрдә һәм авылда. — 5 сәгать<br>IV Моя Родина** | | | |
| 59–61 | Россия һәм Татарстан шәһәрләре.<br>Безнең шәһәр | 3 | Россия, Татарстан шәһәрләре исемнәрен дөрес әйтә белү. Исемнәрне юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешендә куллану күнекмәләрен камилләштерү. Нинди транспортта барганыңны әйтә белү |
| 62–63 | Авылда | 5 | Авылны сурәтли белү. Исемнәрне юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешендә куллану күнекмәләрен камилләштерү. |
| **Җәй җитә. — 3 сәгать<br>III Мир вокруг меня** | | | |
| 64–66 | Күңелле җәй.<br>Габдулла Тукай. «Бала белән күбәләк» | 3 | Җәй билгеләрен әйтә, уенга чакыра, көн нинди булуын әйтә белү. «Бала белән күбәләк» шигырен сәнгатьле укый белү |

## Дәресләрдә куллану өчен дидактик уеннар

**1. «На воздушном шаре» уены.**

— Ребята, мы на воздушном лайнере отправляемся в путешествие. По правилам игры нужно делать посадку только в городах Татарстана.

Балалар самолетта очкан хәрәкәтләр ясыйлар, укытучы төрле шәһәр исемнәрен атый. Укытучы Татарстан шәһәрен атаганда, укучылар чүгәлиләр һәм шәһәр исемнәрен хор белән кабатлыйлар. Шул ук вакытта Россия һәм чит илдәге шәһәр исемнәрен аера һәм әйтә белү күнекмәләре камилләштерелә.

**2. «Угадай» уены.**

Бер бала шәһәр исемен уйлый. Калганнары нинди шәһәр икәнен белергә тиеш.

— Бу Казанмы?

— Бу Казан түгел, бу — Зәй.

**3. «Белмәмеш» уены**. Укытучы сан язылган карточкаларны күрсәтә һәм Белмәмеш исеменнән аны ялгыш итеп әйтә. Мәсәлән, 7 саны язылган карточканы күрсәтә һәм 6 дип әйтә. Балалар төзәтәләр: «Юк, бу 6 түгел, бу — 7».

**4. «Угадай число» уены.** Укытучы сан әйтә, ә балалар бу санга кадәр булган һәм аннан соң килүче санны әйтәләр.

**5. Уен.** Укытучы микъдар санын күрсәтә, укучылар тәртип санын әйтергә тиеш.

**6. Уен.** Укучылар бер рәткә тезелеп басалар, һәм физкультура дәресендәге кебек, һәрберсе үзенең урынын тәртип саны белән атый. Беренче, икенче һ.б.

**7. «Тылсымлы тартма» уены.**

Балалар тартмадан уенчыклар яисә рәсемнәр алалар. Ничәнче уенчыкны алуларына карап, аның исемен һәм тәртип санын әйтәләр.

— Беренче — куян, икенче — аю һ.б.

**8. «Нәрсә артык?» уены**.

Фланелеграфка уку-язу әсбапларының һәм гөмбә (чәчәк) рәсемнәре беркетелә.

— Ребята, что здесь лишнее? Почему?

(Уен барышында уку-язу әсбапларының исемнәре кабатлана.)

**9. Уен.** Укытучы предмет рәсемнәрен күрсәтә, балалар сорау куя.

Куян рәсеме — нәрсә? Кыз рәсеме — кем?

**10. «Сумкада нәрсә бар?» уены**. Укытучы балалар янына килә, аларга сораулар бирә:

— Сумкада каләм бармы?

— Әйе, сумкада каләм бар.

— Сумкада аю бармы?

— Сумкада аю юк.

**11. Шул ук уен укучы белән укучы арасында уйналырга мөмкин.**

**12. «Матур сөйләшәбез» уены.** Укучылар предметларның исемнәрен әйтәләр һәм аларны үзләренә сорап алалар:

— Бу — китап.

— Миңа китап бир әле.

**13. «Строка внимательных» уены.** Сейчас вам придется быть очень, очень внимательными. Если я подниму левую руку вверх, вы называете диких животных, а если подниму вверх правую руку — назовёте домашних животных.

**14. Уен.** Уенчыклар (кыргый хайваннар һәм йорт хайваннары) я аларның рәсемнәре буталып бирелә. Укучылар чиратлашып рәсемне (уенчыкларны) алалар, хайваннарның исемнәрен атыйлар һәм кайда яшәвен әйтәләр.

— Бу төлке. Ул урманда яши.

— Бу сыер. Ул авылда яши.

**15. Уен.**

— Ребята, представьте себе, что вы артисты кукольного театра. Озвучьте животных. Как скажет каждое животное, кто он и где живёт.

— Мин аю. Мин урманда яшим.

— Мин үрдәк. Мин авылда яшим.

— Мин фил. Мин зоопаркта яшим.

**16. Уен.** Фланелеграфка хайваннар, кошлар рәсеме куела. Диалоглар:

а) — Монда ат бармы?
— Әйе, монда ат бар.

ә) — Бу атмы?
— Юк, бу ат түгел.

**17. Физкультминутка** өчен «Чебиләр зарядкасы» җырының 1 нче куплеты һәм кушымтасын алырга мөмкин.

Нәни чебиләр барсы да
Сары майка кияләр.
Зарядка ясарга диеп
Бер урынга киләләр.

Корт-корт, корт-корт,
Сары майка кияләр.
Корт-корт, корт-корт,
Бер урынга киләләр.

**18. «Бу кемгә?» уены**. Укытучы уку-язу әсбаплары рәсемнәрен өстәлгә таратып куя. Укучы рәсемне ала һәм сорый: «Бу кемгә?» Балалар җавап бирәләр: «Нинага». (Нина уенчык ала һәм әйтә: «Бу уенчык миңа».)

**19. Уен**. Уен өчен уенчыклар һәм рәсемнәр әзерләнә.

— Ребята, у нас сегодня конкурс-отбор артистов для озвучивания роли животных из разных сказок. Каждый из вас по очереди выходит и выбирает рисунок (игрушку) с изображением животного или птицы. Лиса из сказки «Болтливая утка» возвращается из деревни, как она об этом скажет.

— Мин авылдан кайтам.

Медвежонок возвращается из лесной школы.

— Мин мәктәптән кайтам.

Заяц из мультфильма «Ну погоди» участвовал в кроссе и возвращается.

— Мин кросстан кайтам.

Кот Матроскин из мультфильма «Простоквашино» возвращается из города. Как он об этом скажет?

— Мин шәһәрдән кайтам.

Волк возвращается из стадиона. Как он скажет?

— Мин стадионнан кайтам.

**20. Уен.** Укытучы өстәлендә уенчыклар яисә рәсемнәр. Балалар чиратлашып өстәлдән уенчыкны алалар. Уенчыкны алганда: «Бу — минем куяным. Бу — минем этем», — дип әйтәләр.

**21. Рифмовка** өйрәнү.

Акбай бик тиз йөгерә,
Менә шулай сикерә.
Кил, Акбай, кил янымa,
Сыйпыйм сине тагын да.

Балалар рифмовканы хәрәкәтләр белән күрсәтеп сөйлиләр. Аны физкультминут итеп тә кулланырга мөмкин.

**22. Уен.**

— Ребята, вспомните, в каких сказках встречаются овощи. Овощ назовите по-татарски, а название сказки — по-русски. Например, кабак — «Золушка»; помидор, суган — «Чипполино», шалкан — «Репка».

**23. «Нәрсә юк?» уены.** Укытучы балаларга яшелчә рәсемнәре күрсәтә. Аннан соң берсен сиздермичә генә яшерә. Балалар нәрсә юк икәнен әйтергә тиеш.

**24. «Баскыч» уены.**

Бу уен аша яшелчә исемнәре истә калдырыла.

Бер бала чыгып, яшелчә исемен әйтә. Мәсәлән, кишер. Икенче бала, аның янына басып, ул әйткән сүзне кабатлый һәм үзе уйлаган яшелчә исемен әйтә. Ул беренче баланың алдына баса. Өченче бала бу ике баланың һәрберсе янына басып, аларның сүзләрен әйтә һәм икенче баланың алдына басып, үзе уйлаган сүзне әйтә. Балалар шулай баскыч төзиләр, яшелчә исемнәрен әйтәләр. Бу уен балаларның игътибарын, хәтер күләмен үстерү өчен дә бик файдалы.

**25. Балалар арасында уен формасында диалогик сөйләм оештырыла.** Укытучы һәрбер балага яшелчә рәсемнәре тарата. Укучылар арасында түбәндәге диалог оештырыла:

— Оля, миңа кыяр бир әле. Мин кыяр яратам.

— Мә.

— Рәхмәт.

**26. Рифмовка— «Без чәчәбез яшелчә».**

Рифмовка хәрәкәтләр белән күрсәтеп сөйләнелә. Аны физкультминут итеп файдаланырга була.

Без чәчәбез яшелчә:
Кишер, кыяр, кәбестә.
Су сибәбез, су сибәбез.
Алар үсә дә үсә.

Күктә кояш елмая,
Җылы яңгырлар ява,
Рәхәт кенә җил исә,
Яшелчәләр зур үсә.

**27. «Не соглашайся» уены.**

— Один из вас придумывает предложение о том , что он любит, а другой говорит, что он этого не любит.

— Мин суган яратам.

— Ә мин суган яратмыйм.

**28. «Ул нинди?» уены** аша диалогик сөйләм үстерү. Өстәлдә яшелчә, җиләк-җимеш рәсемнәре.

— Ребята, по условиям игры, выбрав овощ или фрукт, вы говорите, что любите его и какой он. Потом сами спрашиваете, у кого хотите, что он любит.

Бала үзе теләгән яшелчә яисә җиләк- җимешне сайлап ала һәм әйтә:

— Мин помидор яратам. Ул кызыл, тәмле. Алия, ә син нәрсә яратасың?

**29. «Нәрсә артык» уены.**

Укытучы өстәлендә предмет рәсемнәреннән логик рәт тезелә. Мәсәлән, яшелчә рәсемнәре арасында 1 җиләк-җимеш рәсеме. Укучы логик рәттә нинди предмет артык икәнен табарга һәм аның исемен әйтергә тиеш.

Шул ук уенны бер төрле төстәге предмет рәсемнәрен кулланып уйнарга мөмкин.

30. **«Төрлечә әйт» уены.** Сүзләр, сүзтезмәләр балаларның хәтерендә калсын өчен, уен формасында болай эшләргә була:

а) Ребята, повторите эти слова за мной.

ә) А теперь эти слова произнесём с удивлением.

б) А сейчас — с восхищением.

в) А теперь — шёпотом.

г) Повернулись к друг другу и сообщаем об этих явлениях природы.

д) А теперь повернулись ко мне, я буду говорить по-русски, а вы скажете по-татарски.

**31. «Көн нинди?» уены.** Укытучы сүзләрне әйткәндә, балалар хәрәкәтләр белән күрсәтәләр.

Башта укытучы сүзләрне үзе әйтә, соңыннан укытучы урынына уенны балалар да уздырырга мөмкин. Мәсәлән, салкын — салкыннан калтыранган кыяфәт чыгаралар; кар ява — балалар кар бөртекләре төшкән кебек, әкрен генә чүгәләр; җил исә — куллары белән сулга, уңга хәрәкәт ясыйлар.

**32. Уен.** Укытучы өстәлендә Кыш бабай капчыгы. Анда төрле уенчыклар яисә уенчык рәсемнәре.

— Ребята, я сегодня исполняю роль Деда Мороза. Кто по-татарски спросит, есть ли ему подарок. А когда Дед Мороз покажет подарок, назовёт его по-татарски, тот получит этот подарок.

— Кыш бабай, миңа бүләк бармы?

— Бар (укытучы капчыктан алып күрсәтә).

— Бу куян (укучы атый).

— Мә сиңа куян.

(Укучылар өйрәнә төшкәч, Кыш бабай ролен балалар үзләре үти ала.)

**33. «Уйла һәм әйт» уены.** Укытучы өс киемнәрен әйтә (рәсем күрсәтә). Укучы, үрнәк буенча, тән әгъзасы исемен әйтергә тиеш. Әйтик, бияләй — кул; күзлек — күз; бүрек — баш һ.б.

**34. Физкультминут.**

Укытучы артыннан балалар хәрәкәтләр белән күрсәтәләр.

Песи йоклый.

Песи уяна.

Песи уңга карый, сулга карый.

Песи ашый, песи сөт эчә.

Песи юына.

Песи үсә.

**35. «Мин нәрсә бирәм?» уены.**

Укучыларның өстәлләрендә таратма материаллар (уенчык яисә җиләк-җимеш, яшелчә рәсемнәре). Балалар шуларны файдаланып, җөмләләр төзиләр. Мәсәлән,

— Мин Сашага машина бирәм.

— Мин Розага курчак бирәм.

**36. «Угадай» уены.**

Балаларның өстәлләрендә татар халык ашлары рәсемнәре. Укытучы нинди дә булса ризыкны атый, ә укучылар аның рәсемен күрсәтәләр. Укытучы урынына балалар үзләре уенны алып барырга да мөмкин.

**37. «Кунакка килү» уены.**

— Ребята, как вы думаете, какие сказочные герои к друг другу в гости ходят. Выбирайте себе персонажей и будете их озвучивать.

Балалар укытучы өстәлендәге таратма материалдан Чипполино, Буратино, Винни-Пух, Шүрәле, Күбәләк, Сертотмас үрдәк һ.б. рәсемнәрне алалар һәм кунак каршы алу диалогын сөйләшәләр.

**38. Уен. «Карамыйча әйт».**

Теләк буенча бер укучы такта алдына чыга. Аңа битлек кидерелә. Укучы масканы күрмәскә тиеш. Үзенә нинди битлек кидерелүен ул класска сораулар бирү аша белә ала. Калган укучылар «әйе», «юк» дип җавап бирәләр. Ул белгәч, башка укучы чыга.

Бу очракта кошлар битлекләре белән уйнау өчен сораулар тәкъдим ителә.

— Ул йөриме?

— Ул очамы?

— Ул йөгерәме?

— Ул сикерәме?

— Ул йөзәме?

— Зурмы?

— Кечкенәме?

— Ул карамы?

— Акмы?

— Сорымы?

— Урманда яшиме?

— Авылда яшиме?

— Кишер яратамы? Һ.б. (Балаларның әзерлегенә карап, сораулар төрлечә бирелә).

# ЭЧТӘЛЕК

«Татар теле» укыту-методик комплекты белән эшләү үзенчәлекләре ........ 2

Ишетеп аңлау күнегүләре ........................................................................ 9

Федераль эш программасына нигезләнгән календарь-тематик план ........ 23

Дәресләрдә куллану өчен дидактик уеннар ................................................ 29

*Методическое пособие*

**Хайдарова** Роза Закиевна
**Галиева** Наиля Галиевна

Книга для учителей к учебнику «Татар теле. 1 класс»

1 класс

Редактор:
**Ильгизар Закиев**

Компьютерная вёрстка
**Елены Шараповой**

Подписано в печать 20.08.2024.
Формат 170x205 1/4. Бумага офсетная.
Гарнитура «Arial». Тираж 10 экз. Заказ №

Издательство «Татармультфильм»
420066, г. Казань, пер. Односторонки Гривки, д. 32, помещ. 2

Отпечатано в полном соответствии с качеством
предоставленных материалов в типографии



«Татармультфильм»